| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
| 29.03.2022 | Буа шәһәре | № 69/ИК-п |

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августында 248/Бк-к карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 248/Бк-к номерлы карары белән расланган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына (РФ ГрК) таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 248/Бк-к номерлы карары белән кабул ителгән объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5. бүлекнең 2.5.4 пунктының 2 пунктчксын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) РФ ШрК 55 статьясындагы 3 өлешенең 1, 2, 3 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки алардагы белешмәләр) РФ ШрК 55 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән органнар, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарына буйсынган оешмаларда, әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль тапшырмаган булса, алар карамагында булган оешмаларда соратып алына.;»;

2) 2.8 бүлекнең 2.8.2 пунктының 3 пунктчксын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, моңа Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы 6.2 өлеше нигезендә капиталь төзелеш объекты мәйданын үзгәртү очраклары керми.;».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов